КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 30 март

г.Казань

№ 305

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогка торак сертификаты» гранты турында» 2025 ел, 26 декабрь, 1166 нчы карары белән расланган «Педагогка торак сертификаты» гранты бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогка торак сертификаты» гранты турында» 2025 ел, 26 декабрь, 1166 нчы карары белән расланган «Педагогка торак сертификаты» гранты бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (кararга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 26 декабрь, 1166 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 30 март, 305 нче
карары редакциясендә)

«Педагогка торак сертификаты» гранты бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Педагогка торак сертификаты» гранты (алга таба – грант) бирү максатын, механизмын һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

оешма – Татарстан Республикасы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми һәм (яки) урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы;

махсуслаштырылган оешма – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында «2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары нигезендә билгеләнә торган махсуслаштырылган оешма;

сайлап алуда катнашучы – грант алу өчен сайлап алуда катнашуга гариза (алга таба шул ук эзлеклелектә – сайлап алу, гариза) биргән педагогик хезмәткәр;

грант алучы – җиңүче дип танылган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзегән сайлап алуда катнашучы.

3. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

4. Грант бирүнең максаты – педагогик хезмәткәрләрнең торак шартларын яхшырту.

5. Ел саен һәрберсе 1 млн.сум күләмендә 300 грант бирелә. Грант алучыга грант бер тапкыр бирелә.

6. Грант түбәндәге грант алучылар категорияләренә бирелә:

оешмада мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашыручы тәрбияче;

оешмада ел саен Министрлык тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасында кадрлар ихтыяҗының өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган предмет укытучылары вазыйфалары исемлегенә керүче вазыйфа буенча гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы укытучы;

һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешма мөгаллиме, җитештерү белеме мастеры;

гомуми белем бирү программасы яки урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программасы буенча 0,5 ставкадан кимрәк булмаган күләмдә педагогик эшчәнлек гамәлгә ашыру шартларында оешма җитәкчесе урынбасары.

7. Сайлап алуны үткәрү ысулы – тәкъдимнәр (гаризалар) соратып алу – сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм гаризаларның керү чиратыннан чыгып, сайлап алуны уздыру.

8. Сайлап алу ел саен Министрлыкның сайлап алуны уздыру турында боерыгы белән раслана торган сайлап алуны уздыру сроклары нигезендә, әмма агымдагы елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча уздырыла.

9. Грант бирү нәтиҗәсе – грант акчасын файдаланып, торак объектын милеккә сатып алу яисә ипотека шартнамәсе, кредит оешмасы белән төзелгән кредит шартнамәсе, махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека (максатчан акча заемы) шартнамәсе буенча сатып алынган торак урын кыйммәтен каплау, шул исәптән башлангыч кертем, вакытыннан алда түләү, вакытлы түләүләр һәм (яки) процентлар рәвешендә, максатчан акча заемын (шул исәптән өлешчә заемны) каплау рәвешендә каплау (өлешчә каплау).

Грант бирү нәтиҗәсенә грант бирелгән елның 31 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

10. Грант турында мәгълүмат грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба шул ук эзлеклелектә – «Интернет» челтәре, бердәм портал) һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

11. Грант бирү ысулы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

12. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләре:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба

чаралар турында» 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә сатып алына торган торак урын бәясен (бәясенең бер өлешен) түләү, башлангыч кертемне һәм (яки) даими түләүләрне түләү;

сату-сатып алу шартнамәсе буенча сатып алына торган торак урынның бәясен (бәясенең бер өлешен) (шул исәптән кредит оешмасы белән төзелгән кредит шартнамәсе буенча алынган акчаны файдаланып) түләү;

кредит оешмасы белән төзелгән ипотека шартнамәсе буенча башлангыч һәм (яисә) даими түләүләрне түләү, шул исәптән ипотека шартнамәсе буенча бурычны (бурычның бер өлешен) вакытыннан алда түләү.

13. Сайлап алу критерийлары:

сайлап алуда катнашучыларның югары белеме яки урта һөнәри белеме булу;

сайлап алуда катнашучыларның гариза бирү датасына кимендә өч ел әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән грант алучылар категорияләренә караган вазыйфа буенча эш стажы булу;

сайлап алуда катнашучылар әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән грант алучылар категорияләренә караган вазыйфа буенча, эш вакытының дәвамлылыгы нормасын үтәү шартларында төп эш урыны буенча тиешле хезмәткәрләр категориясе өчен хезмәт законнары ставкасында билгеләнгән вазыйфа буенча оешмаларда хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

сайлап алуда катнашучыларның яше – гариза бирү датасына 50 яшькә кадәр (50 яшьне кертеп);

сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә кертелгән банкротлык процедурасында булмый;

сайлап алуда катнашучылар (сайлап алуда катнашучының ире/хатыны) гариза бирү датасына кадәр соңгы биш ел эчендә торак шартларын начарайтуга китергән гамәлләр кылмаган булу;

сайлап алуда катнашучылар түбәндәге нигезләрнең берсе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы, «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 июль, 587 нче карарларында билгеләнгән тәртиптә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә тора;

махсуслаштырылган оешма реестрында тора һәм Татарстан Республикасы территориясендә торак урын сатып алуга махсуслаштырылган оешма белән ипотека торак кредиты (максатчан акча заемы) шартнамәсе төзегән була;

Татарстан Республикасы территориясендә социаль ипотека (максатчан акча заемы) шартнамәсе, ипотека, кредит шартнамәсе буенча сатып алынган, бердәнбер анықы булган торак урын милекчеләре булып тора, мондый торак урын залог предметы була һәм гариза бирү вакытына йөкләмәләрне үтәү срогы тулы күләмдә җитмәгән, үтәлмәгән йөкләмә күләме кимендә 1 млн.сум күләмендә тәшкил итә;

Татарстан Республикасы территориясендә социаль наем шартнамәсе буенча торак урын яллаучы яки социаль наем шартнамәсе буенча торак урын яллаучы

ире/хатыны яисә торак урын милекчеләре яисә торак урын милекчесенең ире/хатыны булып тормый.

14. Грант бирү шартлары:

сайлап алуда җиңү;

грант алучының йөкләмәсе әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән грант алучылар категорияләренә караган вазыйфа буенча оешмада килешү төзелгән көннән алып кимендә биш ел хезмәт эшчәнлеген башкару. Әлеге срокка грант алучының йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яшькә җиткәнгә кадәр бала карау буенча ял чоры керми.

15. Сайлап алу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр алучыларны сайлап алу башкарыла торган дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2024 ел, 28 ноябрь, 1074 нче карары нигезендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация чепләтәрендә https://subsidiya.tatar.ru/ яки https://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – «Минем субсидияләр» системасы) гамәлгә ашырыла.

16. Министрлыкның һәм гаризаларны карап тикшерү комиссиясенең (алга таба – комиссия) сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Минем субсидияләр» системасында электрон формадагы документларны кулланып гамәлгә ашырыла.

17. Сайлап алуда катнашучыларга «Минем субсидияләр» системасы функцияләреннән файдалану мөмкинлеге, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында «Электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеге тәэмин ителә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (www.gosuslugi.ru) файдаланып, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://subsidiya.tatar.ru/ яисә https://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча яисә «Минем субсидияләр» системасында бастырып чыгарылган «Минем субсидияләр» системасыннан файдалану турындагы килешү буенча мобиль кушымтада гамәлгә ашырыла.

18. Сайлап алуда катнашучы гариза каралган һәм килешү төзелгән датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган физик затлар исемлегендә тормый;

сайлап алуда катнашучы БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле физик затлар исемлегендә тормый;

сайлап алуда катнашучы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре

түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмый;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

19. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерү «Минем субсидияләр» системасында сайлап алу үткәрүне тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары мәгълүматлары нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

20. Министрлык, ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булганда, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 18 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны (әгәр сайлап алуда катнашучы әлеге документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш) таләп итәргә хокуксыз.

21. «Минем субсидияләр» системасында сайлап алу турында белдерү урнаштыру бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында грант турында мәгълүмат урнаштыру датасыннан соң гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, Министрлык җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән зат тарафыннан имзасы куелганнан соң һәм бердәм порталда грант турында мәгълүмат урнаштырылганнан соң бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан бердәм порталда, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Минем субсидияләр» системасында урнаштырыла.

Министрлык, сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Минем субсидияләр» системасында урнаштырылган көннән соң килә торган көннән алып өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган сайт бите турында, аны гамәлдән чыгару турында мәгълүмат, сайлап алу барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат бастырып чыгара.

22. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формалары тутырылу юлы белән электрон рәвештә формалаштырыла, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

гаризалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10нчы календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;
әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәсе;
«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яки) битләр күрсәткечләре;
сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 18 пункты белән билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;
грант алучылар категорияләре һәм сайлап алу критерийлары;
гаризалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 27 – 30 пунктлары нигезендә гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;
әлеге Тәртипнең 32 пункты нигезендә гаризаларны кире алу тәртибе, гаризаларны кире кайтару (шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, гаризага үзгәрешләр кертү тәртибе;
әлеге Тәртипнең 33 – 38 пунктлары нигезендә гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләре;
эшләп бетерү өчен гаризаларны кире кайтару тәртибе;
гаризаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;
әлеге Тәртиптә билгеләнгән сайлап алу кысаларында бүленә торган грант күләме, сайлап алу нәтиҗәләре буенча грант бүлү кагыйдәләре һәм аны үткәрү нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;
сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;
грант алучы тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;
сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;
бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру срогы (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңрак була алмый).
23. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипнең 22 пунктында каралган сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибенең шундый ук тәртибендә, гаризаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:
гаризалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән алып гаризаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;
сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;
сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, гаризалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә әлеге Тәртипнең 32 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларның гаризага үзгәрешләр кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;
гариза биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Минем субсидияләр» система-

сыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

24. Министрлык, табигый яки техноген һәлакәтләр, хәрби хәрәкәтләр, вәкаләтле орган тарафыннан гадәттән тыш дип танылган башка хәлләр белән бәйле рәвештә барлыкка килгән, җиңеп булмый торган вакыйгалар килеп чыккан очракта, сайлап алуны гамәлдән чыгаруны гамәлгә ашыра.

25. Министрлык тарафыннан бердәм порталда сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

26. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү кәгазь документ рәвешендә булдырыла, Министрлык җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән зат тарафыннан үз кулы белән имза куела һәм сканер аша чыгарыла, «Минем субсидияләр» системсында, бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Гаризалар биргән сайлап алуда катнашучыларга «Минем субсидияләр» системасында сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат бирелә.

Бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштырылган көннән алып сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

Әлеге Тәртипнең 20 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрмәү срогы тәмамланганнан соң һәм грант алырга теләүче белән килешү төзелгәнгә кадәр Министрлык җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына Россия Федерациясе Граждан кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә сайлап алуны гамәлдән чыгарырга мөмкин.

27. Сайлап алуда катнашучылар сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән сроклар эчендә «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру һәм «Минем субсидияләр» системасына түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) кертү юлы белән электрон рәвештә гариза булдыра һәм тапшыра:

сайлап алуда катнашучының һәм аның иренең/хатынының шәхесен раслый торган документлар күчермәләре;

никах турында таныклык күчермәсе (булганда);

оешма белән хезмәт шартнамәсе күчермәсе һәм сайлап алуда катнашучыны вазыйфага билгеләү турында боерык күчермәсе;

эш бирүче тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясы нигезендә эш бирүче тарафыннан булдырыла торган хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында белешмәләр);

сайлап алуда катнашучының белеме һәм квалификациясе турында документ күчермәсе;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында сайлап алуда катнашучының теркәлүен раслый торган документ күчермәсе;

сайлап алуда катнашучының финанс шәхси счеты күчермәсе. Әлеге күчермә күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешма (индивидуаль эшкуар)

тарафыннан таныкланган бирелү датасыннан алып бер ай эчендә гамәлдә булырга тиеш. Сайлап алуда катнашучы һәм (яки) аның ире/хатыны төрле адреслар буенча яшәү урынында теркәлгән очракта, финанс счет күчермәсе (яки сайлап алуда катнашучы һәм аның гаилә әгъзалары яшәгән торак урында теркәлгән затларның саны турында мәгълүмат булган башка документ) һәр адрес буенча тапшырыла;

сайлап алуда катнашучының яшәү (булу) урыны буенча теркәлү турында белешмәләр;

Татарстан Республикасы территориясендә сайлап алуда катнашучының яшәү урынынраслый торган документ (суд карары, торак урын арендасы (наемы) шартнамәсе) күчермәсе – яшәү (тору) урыны буенча теркәлмәгән затлар өчен;

сайлап алуда катнашучының торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булуын раслый торган документ (санап үтелгәннәрнең берсе):

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы, «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 июль, 587 нче карарларында билгеләнгән тәртиптә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак сайлап алуда катнашучының исәптә торуын раслый торган документ;

сайлап алуда катнашучының махсуслаштырылган оешма реестрында торуын һәм Татарстан Республикасы территориясендә торак урын сатып алу өчен махсуслаштырылган оешма белән социаль ипотека (максатчан акча заемы) шартнамәсе төзүен раслый торган документ;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы территориясендә социаль ипотека (максатчан акча заемы) шартнамәсе, кредит шартнамәсе буенча сатып алынган, аңа караган бердәнбер торак урын милекчесе булуын раслый торган документ; мондый торак урын залог предметы булып тора һәм гариза бирү вакытына йөкләмәләрне үтәү срогы тулы күләмдә чыкмаган була;

тиешле документны бирү датасына карата сайлап алуда катнашучының социаль наем шартнамәсе буенча торак урынны яллаучы яки социаль наем шартнамәсе буенча торак урынны яллаучының ире/хатыны булып тормавын раслый торган, вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән документ;

ирнең/хатынның Министрлык тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм аңа карата адреслы-белешмә мәгълүмат алуга ризалыгы;

Күчемсез мөлкәт бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган (була торган) күчемсез мөлкәт объектларына аерым зат хокуклары турында яисә рәсми соратыла торган белешмәләрнең Күчемсез мөлкәт бердәм дәүләт реестрында булмавы турында белешмәләр.

28. Гаризада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында түбәндәге мәгълүмат һәм документлар:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вазыйфасы;

салым түләүченең идентификация номеры;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен

почта адресы һәм электрон почта адресы;

грантны күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешү кул куюга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән гариза турында, шулай ук «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган, тиешле сайлап алуга һәм грант бирү нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенең тәкъдим ителә торган күрсәткече, сайлап алуда катнашучы тарафыннан сорала торган грант күләменең сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән максималь (минималь) күләменнән югары (түбән) була алмый торган күрсәткече;

д) сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән һәр сайлап алу критерие турында мәгълүмат, мондый мәгълүматны раслый торган белешмәләр, документлар һәм материаллар.

29. Гариза сайлап алуда катнашучының яки ул вәкаләт биргән затның «Электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган исәпкә алу язмасындагы гади электрон имзасы белән имзалана.

Гаризадагы мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

30. Гаризага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны яисә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яки технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яки сакланган булмаска тиеш.

31. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан гариза бирү датасы һәм вакыты булып «Минем субсидияләр» системасында гариза бирүче тарафыннан гаризага, теркәлү номеры бирелеп, имза кую датасы һәм вакыты санала.

32. Гаризага үзгәрешләр кертү яки гаризаны кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 27 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы гаризасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

33. Сайлап алуда катнашучылар бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән алып, гаризалар тапшыру тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка «Минем субсидияләр» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү

турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында иң күбе биш рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

Министрлык, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, әлеге белдерүдә билгеләнгән срок эчендә, әмма гаризалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Минем субсидияләр» системасында формалаштыру (техник мөмкинлекләр булганда) яки Министрлыкның электрон почтасы адресына кергән рәсми сорау өчен машинкада басыла торган, Министрлык җитәкчесенең яки аның вәкаләтле затының электрон имзасы белән имзалана торган җавап булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә.

Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Минем субсидияләр» системасында формалаштырыла торган аңлатманы, шулай ук әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә Министрлык тарафыннан электрон почта белән җибәрелгән аңлатманы карау мөмкинлеге барлык сайлап алуда катнашучыларга «Минем субсидияләр» системасының гомуми файдалану урынында, Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда катнашучылардан кергән барлык рәсми сораулар һәм аларга җибәрелгән аңлатмалар урнаштыру юлы белән бирелә.

34. Министрлык гаризаларны карау һәм бәяләү максатларында кимендә биш әгъза составында комиссия төзи. Комиссиянең составы һәм эш тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.

Комиссия составына Министрлык вәкилләре, башка республика башкарма хакимият органнары вәкилләре, җирле үзидарә органнары вәкилләре, педагогик хезмәткәрләр керә, шулай ук мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри берлекләре вәкилләре, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет, башка органнар һәм оешмалар вәкилләре кертелергә мөмкин.

Комиссия аның рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретареннан һәм әгъзаларыннан төзелә.

Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия карарын раслый.

Комиссия рәисе булмаганда, аның функцияләрен аның кушуы буенча комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия секретаре комиссия эшчәнлеген оештыру функцияләрен башкара.

Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Туганлык элемтәләре, хезмәт мөнәсәбәтләре, торак урын сату-сатып алу шартнамәсе буенча мөнәсәбәтләр, кредит шартнамәсе, социаль ипотека (максатчан акчалата заем) шартнамәсе, комиссия әгъзасы һәм сайлап алуда катнашучы арасында ипотека шартнамәсе буенча мөнәсәбәтләр белән бәйле барлыкка килгән мәнфәгатьләр конфликты булганда, комиссия әгъзасы мәнфәгатьләр конфликты барлыгы билгеле булган вакыттан кичекмәстән бу хакта комиссия утырышында рәислек итүчегә хәбәр итәргә тиеш һәм тиешле сайлап алуда катнашучыны сайлап алу турында карар кабул

итүдә катнаша алмый. Комиссиянең тиешле әгъзасы сайлауда катнашучының үзенә карата мәнфәгатьләр конфликты булган гаризасын карaганда, киңәш бирү тавышы хокукыннан башка, тавыш бирүдә катнашу хокукыннан башка катнашырга мөмкин.

35. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән гаризалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Минем субсидияләр» системасында Министрлыкка, шулай ук комиссиягә аннан файдалану мөмкинлеге бирелә.

Гаризаларны карап тикшерү «Минем субсидияләр» системасында Министрлыкка һәм комиссиягә гаризаларны карап тикшерү өчен мөмкинлек бирелгән көннән соң килә торган 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Комиссия әлеге Тәртипнең 13 пунктында билгеләнгән сайлап алу критерийлары нигезендә гаризаларны карап тикшерүне гамәлгә ашыра.

36. Комиссия, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән гаризаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, гаризаларны ачу беркетмәсенә кул куя, анда сайлап алуда катнашу өчен кергән гаризалар турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

гаризаның теркәлү номеры;

гариза керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

сайлап алуда катнашучының адресы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан сорала торган грант күләме.

Гаризаларны ачу беркетмәсе кәгазь документ рәвешендә булдырыла һәм комиссия рәисенең үз кулы белән имзасы куела, алга таба «Минем субсидияләр» системасына сканер аша чыгарылган күчермәсе урнаштырыла, шулай ук кул куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

37. Гариза, әгәр ул сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әлеге Тәртипнең 38 пунктында каралган гаризаны каубл итмәү өчен нигезләр булмаганда, дөрес дип таныла.

38. Гаризаларны карап тикшерү стадиясендә гаризаны кабул итмәү өчен нигезләр:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан гаризалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң гариза бирү.

Гаризалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучыларга әлеге Тәртипнең 35 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә комиссия секретаре гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына, гаризаны кабул итмәү нигезләре турында белешмәләр бирелгән комиссия беркетмәсе күчермәсен җибәрә.

39. Сайлап алу түбәндәге очракларда үткәрелмәгән дип таныла:

а) гаризалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер гариза да бирелмәгән;

б) гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык гаризалар кабул ителмәгән.

40. Кергән гаризаларны рангларга бүлү аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла. Әгәр әлеге Тәртипнең 18 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бер көнне гариза бирелгән булса, рангларга бүлү гаризаның бирелгән вакытыннан чыгып башкарыла.

Сайлап алуда җиңүчеләр дип сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән, бүленә торган грант күләме чикләрендә кергән гаризаларны рангларга бүлү нәтиҗәләре буенча ранглар исемлегендә беренче урыннан алып 300 нче урынга кадәр алган сайлап алуда катнашучылар танылa.

41. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчеләрне ачыклау максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе төзелә.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе кәгазь документ рәвешендә төзелә, комиссия рәисенең үз кулы белән имза куела, Министрлык тарафыннан раслана һәм «Минем субсидия» системасында һәм бердәм порталда аңа имза куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында, әмма сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

гаризаның теркәлү номерын, гариза керү датасын һәм вакытын, сайлап алуда катнашучының тулы исемен, юридик зат адресын, сайлап алуда катнашучы тарафыннан сорала торган грант күләмен күрсәтеп, кергән һәм карап тикшерелгән гаризалар саны;

гаризалары дөрес дип танылган һәм карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

гаризалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый гаризалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган грант алучыларның исеме һәм аларга бирелә торган грантның күләме.

42. Министрлык әлеге Тәртипнең 41 пунктында күрсәтелгән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе нигезендә грант бирү турында яки грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм аны, сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә имза куелган датадан алып өч календарь көннән дә соңга калмыйча, боерык белән раслый.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, гаризаларны карап тикшерү беркетмәсенең һәм сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Тәртипнең 41 пунктында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

43. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Министрлык белән грант алучылар

арасында, бердәм порталда һәм «Минем субсидияләр» системасында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе урнаштырылганнан соң 20 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, килешү төзелә.

44. Субсидия бирү турында килешү «Минем субсидияләр» системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы яки гади электрон имзасы белән, ә техник мөмкинлек булмаганда – субсидия бирү турында килешүнең һәр як вәкаләтле затлары тарафыннан үз кулы белән имзалана торган, ике нөсхәдә булган кәгазьдә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максаты;

грант күләме;

грант бирү нәтиҗәсе;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының грант бирү максатын, шартларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечено ирешү турында хисап, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формалары;

грант алучының килешү төзелгән датадан алып биш ел эчендә оешмада әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән вазыйфалар категориясенә керә торган вазыйфа буенча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

килешү төзелгән датадан алып биш ел үткәнгә кадәр оешма белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылган датадан алып өч эш көненнән соңга калмыйча, грант алучының Министрлыкка хәбәр итү йөкләмәсе;

грант түләүне туктату очраклары һәм тәртибе;

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрү сроклары;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык.

45. Килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

46. Килешүгә грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы кертелә.

47. Кирәк булганда Министрлык грант алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

48. Грант алучы, әгәр сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән сроклар эчендә грант алучы исеменнән эш итәргә хокуклы зат тарафыннан килешүгә кул кую тәэмин ителмәгән булса, килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

49. Грант алучыга, шулай ук грант алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, чит ил валютасы алу тыела.

50. Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

51. Әлеге Тәртипнең 50 пунктында күрсәтелгән грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Министрлык, грант алучыга грант бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә грант бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, грант алучыга хәбәрнамә җибәрә.

52. Министрлык, грант бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, грант алучы тарафыннан Россия кредит оешмасында ачылган счетка бер тапкыр акча күчерә.

53. Грант алучылар Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча Министрлыкның урнашу урыны буенча кәгазь рәвешендә яки Министрлыкның электрон почта адресына электрон рәвештә әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап (алга таба – хисап) тапшыра:

грант акчасын махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека (максатчан акчалата заем) шартнамәсе, ипотека шартнамәсе, кредит шартнамәсе нигезендә торак урын бәясе өчен түләү буенча даими түләүләрне һәм (яки) процентларны каплауга файдаланган очракта, квартал саен килешүдә билгеләнгән срок эчендә;

грант акчасын торак урын сату-сатып алу шартнамәсе буенча торак урын бәясен бер тапкыр каплауга (өлешчә каплауга), махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека (максатчан акчалата заем) шартнамәсе, ипотека шартнамәсе, кредит шартнамәсе нигезендә бәяне һәм (яки) процентны каплауга (өлешчә каплауга) файдаланган очракта, бер тапкыр килешүдә билгеләнгән срок эчендә, әмма грант бирелгән елның 29 декабреннән дә соңга калмыйча.

Грант бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапка торак урын сату-сатып алу шартнамәсе, махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека (максатчан

акча заемы) шартнамәсе, ипотека шартнамәсе, кредит шартнамәсе буенча башкарылган түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләре, һәм (яки) махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека (максатчан акча заемы) шартнамәсе, ипотека шартнамәсе, кредит шартнамәсе буенча торак урын бәясен һәм (яки) процентларны каплауны (өлешчә каплауны) раслый торган, махсуслаштырылган яки кредит оешмасы тарафыннан бирелгән документларның күчермәләре теркәлә.

54. Грант алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 53 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән хисап тапшырылмаган очракта, элек түләнгән грант суммасы әлеге Тәртипнең 58 пункты нигезендә грант алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

55. Министрлык әлеге Тәртипнең 53 пунктында күрсәтелгән хисапларны әлеге хисаплар тапшырылган көннән алып биш эш көненнән артмаган срок эчендә тикшерә.

56. Килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүне һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

57. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

58. Хисап финанс елында грантның файдаланылмый калган өлеше, килешүдә каралган очракларда, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Грант акчасы Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәгечә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – грант алучы тарафыннан грант биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешелмәгән, грант бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшырылмаган очракта;

максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган грант күләмендә – грант акчасы максатчан файдаланылмау ачыкланган очракта.

59. Әлеге Нигезләмәнең 57 һәм 58 пунктларында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

60. Грант бирелә торган торак урын грант алучының шәхси милкенә яки грант алучының һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми өлешле милкенә сатып алынырга мөмкин. Торак урын грант алучының һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми өлешле милкенә бары әлеге торак урынны сатып алганда ана (гаилә) капиталы акчасын өстәмә файдалану шарты белән аерым өлешләр бүлеп биреп сатып алына. Грант

алучының һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми өлешле милкенә торак сатып алу максатларында гранттан файдаланганда гаиләнең һәр әгъзасы тарафыннан сатып алына торган торак урын өлеше торак урынның гомуми мәйданының исәпкә алу нормасыннан кимрәк булмаска тиеш.

61. Грант түләү срогы дәвамында эш бирүчене алыштыру әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән категорияләргә туры килә торган вазыйфа буенча оешмага эшкә урнашу шарты белән рөхсәт ителә.

62. Сайлап алуга тапшырылган документлар килешү төзелгән вакыттан алып биш ел дәвамында саклanырга тиеш.

63. Грантны нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.